ГЛАВА ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы Тау, 423181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы, 423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2022 елның «05» нче октябре № 2

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 16 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Тубылгытау гомуми белем бирү мәктәбе янында (Яшьләр ур., 100) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегендә Тубылгы Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 16 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Тынычлык урамы 73 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегендә Тубылгы Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 16 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта Тубылгытау мәдәният йортында (Яшьләр ур., 94А) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегендә Тубылгы Тау авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Тубылгы Тау авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен вакытлыча билгеләр буенча башкарылырга тиеш.
5. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.
6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда үзара салым кертүегез һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугыш ветераны, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 нче төркем инвалидлардан тыш алынган акчаларны Тубылгы Тау авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Мира, Яшьләр урамы, Дуслык урамы буенча;

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- юлларны грейдлау (килешү буенча эшләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».».

7. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылының Яшьләр урамы 73 нче йорт мәгълүмат стендларында урнаштырырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ТУБЫЛГЫТАУСКОЕ
р 00597/14
СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Ф.Ф. Исмәгыйлев